СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
10 июля 2015 года

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№535

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында Зеленодольск шәһәре Советы инициативасын кабул итү хакында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. В. Старостинның Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру инициативасы турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында Зеленодольск шәһәре Советы тәкъдимен кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә вәкаләтләрне кабул итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне, Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты белән гамәлдәге законнар нигезендә, тапшыру турында килешү төзергә.
4. Әлеге карарның 1, 2 пунктлары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары, шулай ук муниципаль районның вәкиллекле органы карарларында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә кулланылган матди ресурслар һәм финанс чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Советының 2015 елның 10 июлендәге**
**535 номерлы карарына**
**1 кушымта**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге башкару өчен кабул ителә торган вәкаләтләр исемлеге**

1) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иректе үтеп керүен тәэмин итү һәм төзекләндерүне оештыру;

2) көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру;

3)Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, шул исәптән алар урнашкан биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен карап тоту таләпләрен, тиешле биналарның һәм корылмаларның фасадларын һәм коймаларын тышкы кыяфәтенә карата таләпләрне, аларны төзекләндерү эшләре исемлеген һәм аларны үтәүнең вакытын билгели; биналарның (эчендәге биналарның) һәм корылмаларның якын-тирә территорияләрен төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, йортлар исемнәре һәм номерлары язылган күрсәткечләр урнаштыру, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту), шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарын, аеруча саклана торган табигать территорияләрен куллану, саклау, яклау, яңадан торгызу, урманнарны, аеруча саклаулы табигать территорияләрен куллану, саклау һәм үстерү;

4) объект адресларына адресларны бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру;

5) җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Советының 2015 елның 10 июлендәге**
**535 номерлы карарына**
**2 кушымта**

**Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты арасында «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында**
**Килешү**

«___» __________ 20__ел                                        _________________

Бер яктан, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Егоров Сергей Геннадьевич, алга таба «район Башкарма комитеты» дип аталучы һәм икенче яктан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Бареев Руслан Рәшит улы, алга таба «җирлек Башкарма комитеты» дип аталучы, бергә «Яклар» дип аталучы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, 52 статьясындагы 3 өлеше “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга таянып, түбәндәгеләр турында әлеге Килешү төзеделәр:

## 1. Килешү Предметы

Әлеге Килешүнең предметы булып җирлек Башкарма комитеты тарафыннан җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен район Башкарма комитетына тапшыру тора:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итүне оештыру;

- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру;

-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, шул исәптән алар урнашкан биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен карап тоту таләпләрен, тиешле биналарның һәм корылмаларның фасадларын һәм коймаларын тышкы

кыяфәтенә карата таләпләрне, аларны төзекләндерү эшләре исемлеген һәм аларны үтәүнең вакытын билгели; биналарның (эчендәге биналарның) һәм корылмаларның якын-тирә территорияләрен төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, йортлар исемнәре һәм номерлары язылган күрсәткечләр урнаштыру, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту), шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарын, аеруча саклана торган табигать территорияләрен куллану, саклау, яклау, яңадан торгызу, урманнарны, аеруча саклаулы табигать территорияләрен куллану, саклау һәм үстерү;

- объект адресларына адресларны бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек Башкарма комитеты район Башкарма комитетына бурычлы:

әлеге Килешүнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар рәвешендә финанс чараларын бирергә (алга таба – тапшырылган вәкаләтләр);

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны бирергә;

район Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашырганда консультация һәм методик ярдәм күрсәтү.

2.2. Җирлек Башкарма комитеты хокуклы:

район Башкарма комитеты тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен, шулай ук әлеге Килешүнең 3 пунктында күрсәтелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотарга. Хокук бозулар ачыкланган очракта, җирлек Башкарма комитеты район Башкарма комитеты тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булган, хәбәр итү мизгеленнән билгеле бер вакытта ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен язма таләпләр җибәрергә хокуклы;

район Башкарма комитетыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шулай ук әлеге максатларга бирелгән финанс чараларын куллану белән бәйле кирәкле мәгълүматлар, материаллар һәм документларны соратып алырга;

район Башкарма комитетына тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кертергә.

2.3. Район Башкарма комитеты бурычлы:

бирелгән вәкаләтләрнең тиешле дәрәҗәдә үтәлешен, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты тарафыннан бары тик тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә

ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны гамәлгә ашырырга (тәэмин итәргә);

вәкаләтләрнең үтәлеше турында вәкаләтләрне үтәү өчен бирелгән финанс чараларыннан файдалану, шулай ук әлеге Килешү предметына кагылышлы башка төрле сораулар буенча җирлек Башкарма комитетына хисап бирергә;

җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турындагы язма таләпләрне бер айдан да соңга калмыйча (әгәр дә таләптә башка вакыт билгеләнмәгән булса), җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта җирлек Башкарма комитетына кичекмәстән хәбәр итәргә;

Килешүнең гамәлдә булуы туктатылган очракта файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә үтәү мөмкин булмаган очракта, бу хакта җирлек Башкарма комитетына язма рәвештә вәкаләтләрне башкару мөмкинлеге булмаганлыктан, ун көн эчендә хәбәр итәргә;

2.4. Район Башкарма комитеты хокуклы:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;

бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Башкарма комитетыннан кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, закон нигезендә, матди ресурслардан һәм башка финанс чараларыннан өстәмә файдаланырга;

бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән гамәлдәге законнарга каршы килми торган теләсә нинди башка гамәлләр кылырга.

## 3. Бюджетара трансфертлар

3.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы “Зеленодольск шәһәре” муниципаль берәмлеге бюджетыннан бюджет законнары нигезендә, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Район Башкарма комитеты тарафыннан финанс чараларны максатсыз файдаланган очракта, алар Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына ун көн эчендә җирлек Башкарма комитеты таләбе буенча кире кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту

4.1. Җирлек Башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен гамәлгә ашыра, район Башкарма комитетыннан бирелгән финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүматны сорый. Район Башкарма комитеты, җирлек Башкарма комитетының дәлилләнгән соравы буенча соратып алына торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Отчетларның формасы һәм аларны бирү тәртибе җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары белән билгеләнә һәм район Башкарма комитеты белән килештерелә.

4.3. Бирелгән финанс чараларын тотуны тикшерү «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе тарафыннан, шул исәптән җирлек Башкарма комитеты запросы буенча гамәлгә ашырыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1. Әлеге Килешү имзаланган көннән үз көченә керә һәм икенче чакырылыш Зеленодольск шәһәре Советы вәкаләтләре вакыты чыкканчы гамәлдә була.

## 6. Килешүнең нигезе һәм вакытыннан алда туктату тәртибе

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

берьяклы тәртиптә:

- бер Якның үз йөкләмәләрен үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве;
- Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарын үзгәрү нәтиҗәсендә, район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне башкару мөмкин түгел, яисә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр җирлек Башкарма комитеты тарафыннан мөстәкыйль, аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүнең өзелүе турында хәбәрнамә башка Якка, аның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы, 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакытыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән файдаланылмаган финанс чараларын җирлек Башкарма комитетына кире кайтара.

6.4. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы, шулай ук законнарда каралган нигезләр буенча туктатыла.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү, законнарда каралган җаваплылык җитүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге Килешү буенча якларның берсе, йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як, әлеге Килешүдә каралган икенче Якка, кушымтада каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә, штраф түли.

7.3. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүдән алга таба азат итми.

## 8. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

8.1 Әлеге Килешүнең үтәлеше белән бәйле бәхәсләр Яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларын куллану юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәсне сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл итү мөмкин булмаганда, ул законнарда каралган башка тәртиптә тикшерелергә тиеш.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә Килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә Килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү ике нөсхәдә, бер үк юридик көчкә ия, һәр Як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

9.3. Әлеге Килешүгә кушымта итеп бирелә:

«Бюджетара трансфертлар күләме» кушымтасы

# 10. Яклар имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |
| __________ / С. Г. Егоров/ | ___________ / Р. Р. Бареев/ |
| «____» __________20__ел | «____» _____________20__ел |

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Зеленодольск шәһәре Башкарма комитеты арасында җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру турында Килешүгә Кушымта**

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле булган бюджетара трансфертлар күләме

Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге бюджетыннан бюджет законнары нигезендә, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме___________ сум.